ГЛАВА ИСКЕ-КАЗАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Куркачи , ул. Клубная , 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Коркачык авылы, Клуб ур.,4

Тел./факс: +7(84365) 70-700, e-mail:.Ikaz.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«02» ноябрь, 2021 ел** **№4**

## Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Коркачык авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 21 октябрендәге 167 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары (19.05.2020 елның 187 номерлы редакциясендә) нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Коркачык авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 18 ноябренә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлегенең Коркачык авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 30 ноябренә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен территориаль билгеләр буенча Коркачык авылы халкы исемлеге түбәндәгечә бүленгән:

а) Беренче этап: Үзәк, Калинин, Садовая урамнары халкы

б) Икенче этап: Совет, Колхоз, Клуб урамнары халкы.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2021 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Коркачык авылы территориясендә

даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне: Коркачык авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм реконструцияләү (су кудыру башнясын, насос станциясен, тышкы суүткәргечне алыштыру),
үтәүгә юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны кабул ителгән көненнән алып 3 көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске-Казан авыл җирлеге
башлыгы Г.Р. Закирова